وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

**№4 (173). 25 гыйнвар 2013 / 13-рабыгыль-әүвәл-1434**

**ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ**



Коръәндә – телләр һәм милләтләр турында ▷2◁



Хәзерге шигърияттә Мифтахетдин Акмулла образы ▷3,4◁



Иманлы кешенең сыйфатлары ▷4◁

# Бәйлелек

**"Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга һәм табынырга лаеклы һичбер илаһ (зат) юк" - һәрбер мөселман яттан белә торган шәһадәтнең беренче сүзләреннән үк Аллаһы Тәгаләгә генә ышануның күп кенә үзенчәлекләре ачыла.**

Бүген без шуларның берсенә - бәйсезлеккә тукталып китәрбез. Төгәлрәк әйткәндә, Аллаһы Тәгалә кушканнардан кала, мөселманнарның бернәрсәгә дә бәйле булмавына. Безнең ниндидер эш башкаруыбыз яки башкармавыбыз башка нәрсәләргә никадәр бәйле? Мәсәлән, намаз кылу - вакытында компьютердан аерыла алудан, намазның чисталыгы - берникадәр вакыт элек хәмер эчемлекләрен тәкъдим иткән вакытта безнең баш тартуыбыздан. Наркотиклар һәм алкоголь кебек бәйлелекләр турында сөйләшкәнче, интернет, татлы ризык, кирәксез телевидение тапшырулары, буш сүзләр сөйләү кебек беренче карашка гади һәм зарарсыз нәрсәләргә никадәр бәйле булуыбызны искә төшерик. Аларны бик күп санарга мөмкин. Иң мөһиме - бу бәйлелекнең дини вазифаларыбызны башкаруга йогынты ясавын яки ясамавын аңлау.

Еш кына интернет форумнарында утыручы мөселман кешесе, кардәшенең иманын тикшереп, аның язганнарын укучы башка кешеләр фикереннән, аларның хуплауларыннан бәйлеккә төшә. Башка кеше фикеренә бәйле булу - шулай ук бәйлелек. Аллаһы Тәгалә Баш хаким түгелмени? Йөрәкләребездә булганны ул гына күрмимени?

Кеше хәмер эчемлекләр эчеп, тормыш авырлыкларыннан качарга омтыла. Зиһене томаланган вакытта аңа бөтен сөйләгән сүзләре дөрес, аны барысы да игътибар белән тыңлый, ярата һәм ул да барлык кешеләрне дә ярата кебек тоела башлый. Эчкече чынбарлык белән аерылып хәмер дөньясында яши башлый. Аралашу өчен шундый ук үз-үзләрен югалтып йөргән кешеләрне таба. Хәмер эчеп, ясалма иллюзияләр белән яши башлагач аек якыннары да кирәкми башлый.

Шундый ук чынбарлыктан читләшү интернетка бәйлелеккә төшкәннәрдә күзәтелә. Андыйлар тормыш алып барырга берниндн көч куймыйча, үзен батыр дип хис итеп, виртуаль дөньяда яши башлый. Бу бәйлелеккә китерә. Чынбарлыкта мондый кешеләр бернәрсә дә башкарырга тырышмый, аларга виртуаль тормыш мөһимрәк була башлый. Виртуаль тормышта ул чынбарлыкта башкара алмаган эшләрне тормышка ашыра - коточкыч җанварларны "үтерү", югалган җаннарны "коткара", теләсә кемне, хәтта президентны, хөрмәтле олуг шәхесләрне урынсыз төнкыйтьләүдән дә тыелып кала алмый. Әле башка кайберәүләр чынлапмы-шаярыпмы аны үсендерә, куәтли башласа тормышы уңды дип исәпләргә була! Кызганыч, бу бары аяныч алдану гына шул.

Компьютер технологияләре кешелек өчен яхшы нәрсә, алар кешеләрнең бер-берсе белән аралашу мөмкинлеген арттыра, бу, әлбәттә, бүгенге заманда өммәткә файда гына китерердәй бер юл. Ләкин күреп торабыз: интернет аралашуларның тискәре яклары да бар. Теләсә нинди бәйлелек, шул исәптән интернетка бәйлелек, бары Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуга гына бәйле булырга тиеш шәхес үсешенә тискәре йогынты ясый. "Кеше илә җенне халык кылмадым, мәгәр Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халык кылдым". (Коръән, "Зарият (Таратучы)" сүрәсенең 56 нчы аяте).

*Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

# Пәйгамбәребезне (сгв) яхшылап белик!

**Әгәр дә: "Бар кешелек тарихында андагы иң бөек кешеләр арасында иң яхшысы кем булган?" - дип үз-үзеңә сорау бирсәң, җавап бер генә: рабигыль-әүвәл аеның 12 нче көнендә, дүшәмбе таңы алдыннан Мәккә шәһәрендә туган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (сгв) булачак. Аның әтисе Габдулла, ә әнисе - Әминә исемле булган. Булачак рәсүлебезнең әтисе - бик тә затлы, атаклы Һашимнар нәселеннән, Кораеш кабиләсеннән.**




Бабасы Габделмотталиб оныгы туу турындагы хәбәрне ишеткәч, ул бу вакыйгага чиксез шатланган һәм онычын Мөхәммәд дип атарга карар иткән.

Мөхәммәд ятим булып үсә: анасы карынында җиде айлык булганда, әтисе вафат була, алты яшендә әнисе Әминә дөньядан китә. Ул Җирдә яшәгән һәм алга таба шушы дөньяга киләчәк бар иң яхшы кешеләр арасында да сайлап алынган зат. Аллаһы Тәгалә үзенең Рәсүленә (сгв) бу дөньяның һәм ахирәтнең бар камиллекләрен дә, башка беркемгә дә бүләк итмәгән кадәр дәрәҗәдә бүләк иткән. Пәйгамбәребез (сгв) бар яктан да камил килгән, аның бар сыйфатлары да югары дәрәҗәдә булган.

Рабигыль-әүвәл аен Аллаһы Тәгалә безнең Пәйгамбәребезнең (сгв) тууы белән зурлаган һәм бизәгән. Бу ай (без - мөселманнар өчен, әлбәттә) шатлык аена да әйләнгән. Бу айда Пәйгамбәребезнең (сгв) тормышын һәм эшчәнлеген өйрәнүдә, аның хакында белемнәр таратуда тырышу лазем.

Пәйгамбәрләрнең соңгысы буларак җибәрелгән Пәйгамбәребез (сгв) бер кешелек өчен генә түгел, барча галәмнәргә Аллаһның бер рәхмәте булып килгән.

Аңа кадәрге пәйгамбәрләр бары тик аерым халыкларга гына җибәрелгән булганнар, алар кертккән кануннарның гамәлдә булу вакыты чикләнгән булган. Алар эшләгән могҗизалар үз чорларының казанышлары булган. Ә Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезгә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) иңдергән Изге Корьән - иң бөек могҗиза, ул Ахырзаманга кадәр үз көчендә калачак. Аллаһның Рәсүле тормышны бар нечкәлекләре белән аңлатып һәм гаделлекне чынга ашырып бар кешелекне коткарган. Әлбәттә, бу аңа җиңел генә бирелмәгән, ул үз юлында төрле каршылыкларга очраган, аңа зур кыенлыклар

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## Мәрҗани мәчетендә "Касыйдәи Бөрдә" укылды

**23 гыйнвар көнне Казанның Мәрҗани мәчетендә мөселманнар Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көнен "Касыйдәи Бөрдә" укып каршы алды. Рабигыль-әүвәл аен халыкта Мәүлид ае дип йөртәләр. Бу айда Мәүлид ашлары үткәрелә. Пәйгамбәребез (сгв) тормышы өйрәнелә һәм салаватлар әйтелә.**

Казан ислам колледжы директоры урынбасары Нияз хәзрәт Сабиров әйтеп киткәнчә, Мәүлидне билгеләп үтә башлау XI-XIII гасырларга карый. Татарстанда һәм Россиядә, гомумән, бөтен дөньяда ислам динен тотучылар тарафыннан тантаналы рәвештә Пәйгамбәрне (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) искә алу чараларын уздыру соңгы елларда бик тә активлашты. "Пәйгамбәрне (сгв) хөрмәт иткән кешеләр Аллаһның ризалыгына, рәхмәтенә ирешә", - дип билгеләп үтте хәзрәт.

Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов, Мәүлидне каршы алырга җыелганнарга мөрәҗәгать итеп, Корьәндә Мөхәммәд галәйһиссәламнең бу галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгәнлеге турында хәбәр ителүен ассызыклады. "Мөхәммәд пәйгамбәр - Аллаһы Тәгаләнең бер нигъмәте. Ул бу дөньяның хәлен үзгәрткән: Аллаһы Тәгаләнең Китабын алып килеп, өммәтне хакыйкый пакълеккә чыгарган кеше", - диде Габдулла хәзрәт.

Нияз хәзрәт Сабиров, кичәне дәвам итеп, Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) күркәм әхлагы турында сөйләде. "Мөхәммәд галәйһиссәлам бер хәдисендә: "Миңа тәрбияне Аллаһы Тәгалә үзе бирде. Ул тәрбия нинди күркәм булды", - дип әйтә. Аның әхлак чыганагы Корьән булган. Безгә Пәйгамбәребезнең (сгв) сөннәтләренә ияреп, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешергә язса иде", - дип белдерде Нияз хәзрәт.

Казан ислам колледжы шәкертләре башкаруында Мөхәммәд галәйһиссәламгә багышланган нәшидләр тыңлаганнан соң, Мәрҗани мәчете имам-хатыйбы Илфар хәзрәт Хәсәнов Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) кешелеккә җибәрелүенең алшартлары белән таныштырып үтте. "Аллаһы Тәгалә адәм балаларын караңгылыктан чыгару өчен, шәм яктысы буларак, Мөхәммәд галәйһиссәламне җибәрде. Аның тормыш рәвешен үрнәк итеп алып, Сөннәт юлыннан барырга язса иде", - дип, үзенең теләкләрен җиткерде.

Тантаналы кичә "Аллаһы Тәгаләгә шөкер булсын!" дип аталган нәшидләр башкарып, Мәүлид уку өчен иң яхшы китаплардан саналган "Касыйдәи Бөрдә"не укып, догалар кылып тәмамланды.

**Чыганак: www.tatar-inform.ru**

# Корьәндә - телләр һәм милләтләр турында

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйткән:

أعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ: ( وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلاَئِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ فِي الأَرْضِ خَلِيفَةً قَالُوا أَتَجْعَلُ فِيهَا مَنْ يُفْسِدُ
فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَآءَ وَنَحْنُ نُسَبِّحُ بِحَمْدِكَ وَنُقَدِّسُ لَكَ قَالَ إِنِّي أَعْلَمُ مَا لاَ تَعْلَمُونَ )

"Һәм әйтте синең Раббың фәрештәләргә: "Мин, әлбәттә, җир өстендә хәлифә итеп Адәмне кылмакчымын. Фәрештәләр әйттеләр: "Ий, Раббыбыз! Бозыклык кылучы, сугышып кан түгүче затны җир өстенә хәлифә кыласыңмы? Без исә Сине мактап тәсбихләр әйтәбез, һәм Сине һәр кимчелектән пакьсең дип игътикад итәбез". Аллаһ фәрештәләргә: "Дөреслектә, Мин сез белмәгәнне беләмен", - диде". ("Әл-Бәкара" сүрәсенең 30 нчы аяте).

"Әл-Бәкара" сүрәсенең дәвамында Раббыбыз болай ди:

( وَعَلَّمَ ءادَمَ الأَسْمَآءَ كُلَّهَا ثُمَّ عَرَضَهُمْ عَلَى المَلاَئِكَةِ فَقَالَ أَنبِئُونِي بِأَسْمَآءِ هَؤُلاَءِ إِنْ كُنْتُمْ صَادِقِينَ )

"Аллаһы Тәгалә Адәмгә исемнәрнең барчасын өйрәтте дә, фәрештәләргә әйтте: "Әгәр дөрес сөйләүчеләрдән булсагыз, Адәм белгән исемнәрнең барчасын әйтеп бирегез" ("Әл-Бәкара" сүрәсенең 31 нче аяте).

Аятьләрдән күрүебезчә, җиргә хәлифә итеп куйганчы Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламгә барча әйберләрнең, мәхлукларның, аларның җенесләренең исемнәрен өйрәтте. Ягъни барча сүзләрне. Һәм галимнәребез әйткән: монда барча сүзләр мәгънәсендә Адәм галәйһиссәламгә барча телләрнең өйрәтелүе әйтелә. Фәрештәләр Аллаһы Тәгаләгә: "Я, Раббыбыз, без Сиңа тәсбих кылабыз, Сине олылыйбыз. Син Җир йөзенә кан коючыны һәм бозыклык таратучыны хәлифә итеп куясыңмы?!" - дигәч, Аллаһ Тәгалә әйтте: "Бу әйберләрнең исемнәре хакында хәбәр бирегез, әгәр тугры булсагыз". Адәм галәйһиссәламнең фәрештәләрдән өстенлеге шунда күренде.

Моннан аңлашылганча, телләрне, барча әйберләрнең исемнәрен белү - ул гыйлем санала һәм гыйбадәткә караганда гыйлем өстенрәк. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай ди:

( وَمِنْ ءَايَاتِهِ خَلْقُ السَّمَاوَاتِ وَالأَرْضِ وَاخْتِلاَفُ أَلْسِنَتِكُمْ وَأَلْوَانِكُمْ إِنَّ فِي ذَلِكَ لآيَاتٍ لِلْعَالِمِينَ )

"Аллаһы Тәгаләнең олуглыгының һәм кодрәтенең билгеләреннән күкләрне һәм җирне яралтуы, һәм телләрегезнең һәм үзегезнең төрле булуыгыз. Белүчеләр өчен бу әйберләрдә билгеләр бар". ("Әр-Рум" сүрәсенең 22 нче аяте).

Ягъни, Адәм балаларының төрле төстә, төрле телдә булуы - ул Аллаһы Тәгаләнең кодрәте һәм бөеклеге билгеләре. Әлбәттә, аңлаучылар өчен. Һәм бу телләрнең һәм төсләрнең аермалыгы адәм балаларының бер-берсен аерсыннар өчен. Бер атадан һәм анадан булуларына карамастан, Аллаһы Тәгалә аларны төрле-төрле итте. Бу әйберләр - хикмәт өчен. Аллаһы Тәгаләнең һәр эше хикмәтле. Кайберәүләр: "Исламда тел вә милләт юк", - ди. Әмма Коръәндә тел дә, милләт тә бар. Аллаһның Китабында халыклар, аларның телләре һәм төсләре бер-берегезне тану өчен - Аллаһның билгеләре, дип әйтелгән. Менә Раббыбыз нәрсә дип эндәшкән Адәм балаларына:

(يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِن ذَكَرٍ وَأُنثَى وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوباً وَقَبَآئِلَ لِتَعَارَفُوا إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ
إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ )

"Ий кешеләр, Без сезне ир вә хатыннан яралттык, вә сездән халыклар вә кабиләләр кылдык бер-берегезне танып, белер өчен. Дөреслектә, Аллаһ хозурында хөрмәтлерәгегез - тәкъвалырак булганыгыз. Дөреслектә, Аллаһ һәр нәрсәне белүче вә һәр эшегездән хәбәрдар". ("Әл-Хуҗурат" сүрәсенең 13 нче аяте).

Аллаһы Тәгалә безне төрле халыклар, кабиләләр кылды, бер-беребезне тану, ярдәмләшү өчен. Ә бер-беребездән көлү яисә бер-беребезне кимсетү, мәсхәрә итү, берсен икенчесеннән өстенрәк кылып золым китерү өчен түгел. Аллаһы Тәгаләгә якынлыгыбыз нинди телдә сөйләшүебезгә бәйле түгел, ә бәлки тәкъвалыгыбызга бәйле. Тел - ул фәкать халыкларны аеручы билге һәм ул бер милләтне, кавемне берләштерүче булып тора. Шуңа күрә дә кем нинди телдә сөйләшә-аңлаша икән - ул шул халыктан. Бу гыйбарәне кайбер гарәп галимнәре хәдис дип тә, риваять дип тә әйткәннәр. Ягъни кем гарәпчә аңлашса, шул гарәп, дигәннәр. Шуңа нигезләнеп, кем рус телендә генә аңлашса - ул рус, татарча аңлашса - татар, башкортча аңлашча - башкорт, дип әйтү дөрес була. Әлбәттә, үз милләтең теленә өстәп, башка телләрне белү - ул зур мәртәбә. Коръән һәм Пәйгамбәребезнең (сгв) сөннәте гарәп телендә булганлыктан, ахирәт бәхетенә ирешү өчен бу телне дә белү кирәк. Башка милләтләр белән аралашу, алар арасында динебезгә дәгъвәт кылу өчен аларның телләрен дә белү зарур. Әмма үз милләтеңнең телен читкә этәрү, аны кыерсыту хисабына түгел. Киресенчә, һәркем үз милләте телендә ачык, матур итеп сөйләшә белергә тиеш. Муса галәйһиссәлам Фиргавен янына барганда Аллаһы Тәгаләдән Һарунны үзе белән бергә җибәрүен үтенде. Чөнки Муса галәйһиссәлам сакаурак, ә Һарун бик ачык, матур итеп сөйләшә иде.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) әйткән: "Кем нинди кавемгә, халыкка охшарга тырышса, ул алардан булыр". Башка милләтләргә охшарга тырышканнарның бу омтылышы сөйләшүләрендә генә түгел, ә йөзләрендә, киенүендә, үз-үзләрен тотышында да күренә. Татар (мөселман) мәктәпләре, балалар бакчалары була торып, үз баланы чит телдә генә сөйләшергә өйрәтү, шул халыкның гореф-гадәтләрендә тәрбияләү - бу, әлбәттә, монафикълык билгесе һәм ул шулай ук мөселман кардәшләреңә, үз милләтеңә хыянәт тә.



Бервакытны Пәйгамбәребез (сгв) янына сәхабәләрдән булган бер егетне китергәннәр һәм болай дигәннәр: "Йә, Рәсүлуллаһ, бу егет җиде сүрәне яттан белә". Пәйгамбәребез (сгв) аңа бик гаҗәпләнгән һәм сокланган һәм: "Миңа яһүдләрдән язулар килә. Үзләренә дә язулар җибәрергә туры килә. Алар алдамасыннар өчен яһүд язуын өйрән", - дигән. Һәм теге егет шулай эшләгән, ягъни телне өйрәнгән. Шуннан соң Пәйгамбәребез (сгв) сораган: "Син сирьян телен беләсеңме?" Ул гарәпләр белән византиялеләр арасында яшәүчеләрнең теле булган. Егет: "Юк", - дип җавап биргән. Пәйгамбәребез (сгв) егеткә шул телне өйрәнергә кушкан һәм егет аны унҗиде көндә өйрәнгән. Ягъни, дини зарурият булу сәбәпле, динне тарату өчен башка телне өйрәнергә рөхсәт ителә. Фәкать шул шарт белән. Гомәр (рг) әйткән: "Йолдызлар гыйлемен өйрәнегез - юлларны белү өчен. Нәсел-нәсәбегезне, үзегезнең кайдан чыкканыгызны, нинди халыктан булуыгызны, телләрегезне өйрәнегез - бер-берегезгә якынайта торган сәбәп булсын өчен". Үз ата-бабаң телен санга сукмау, аны өйрәнмәү - ул инде мөселман халыклары булган татар, башкортлан ерагайта, ә икенче бер чит милләткә - мөселман булмаганнарга якынайта.

***Рафикъ хәзрәт МИҢНӘХМӘТОВ,***
***Татарстанның көнчыгыш төбәге казые, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы әгъзасы, Әлмәт районы имам-мөхтәсибе***

# Пәйгамбәребезне (сгв) яхшылап белик!

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

һәм югалтулар кичерергә туры килгән. Тик пәйгамбәрләрнең тәкъдире шундый - алар язмышына иң зур сынаулар туры килгән: аларны эзәрлекләгәннәр дә, үтергәннәр дә, төрле газапларга да дучар иткәннәр. Тик пәйгамбәрләрне Аллаһы Тәгалә юлыннан берни дә чигендерә алмый.

Пәйгамбәрләр үзләренең рухи камиллекләре, күрсәтмәләре һәм игелекле үгет-нәсыйхәтләре аркасында гына Җирдә яшәүчеләр үзләренең кешелек кыяфәтләрен саклап кала алган. Әлбәттә, бу - Аллаһы Тәгаләнең адәм балаларына булган рәхмәте аркылы.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (сгв) пәйгамбәрләрнең соңгысы, аннан соң инде башка пәйгамбәр килмәячәк. Соңгы Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) бик күп күркәм исемнәре бар. Бохари, Мөслим һәм Тирмизи тапшырган хәдистә: "Минем биш исемем бар: мин - Мөхәммәд; мин - Әхмәд; мин - Маһи, ягъни имансызлыкны юкка чыгаручы; мин - Хәшир, ягъни иң беренче булып кубарылучы; мин - Акиб, ягъни шул кеше ки, миннән соң башка пәйгамбәр булмаучы", - диелә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (сгв) - дөньяда иң зур хөрмәт күрсәтелүче һәм иң абруйлы кеше. Аның исеме Аллаһы Тәгаләдән кала иң күп искә алына. Җир шарының бар почмакларында да һәрвакыт Аллаһның Рәсүлен (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) данлап, салаватлар әйтелә. Башка бер генә кешенең исемен дә ул кадәр еш телгә алмыйлар. Аллаһның берлегенә шәһадәт китерү белән бергә, мөселманнар Мөхәммәднең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Рәсүл булуына да шәһадәт әйтәләр. Дөньяның бар мәчетләрендә дә көненә биш тапкыр намазга чакыралар, миллионлаган мөселманнар Кәгъбәгә таба йөзләрен юнәлтеп намаз укыйлар.

**НАМАЗ**

Намаз - ул Бердәнбер Аллаһка табыну. Намаз укырга Пәйгамбәребезне (сгв) Җәбраил (гс) өйрәткән, ә Пәйгамбәребез (сгв), үз чиратында, - башка мөселманнарны. Шул вакытлардан алып, намаз уку - Аллаһны һәм Аның Рәсүлен танудан кала, һәр мөселманнар өчен фарыз гамәлләрнең иң мөһимендә әверелгән. Һәм һәр мөселман үзенең көндәлек режимын бар намазларны да вакытында укырлык итеп төзергә тиеш.

**ИЗГЕ КОРЪӘН**

Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезгә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Изге Коръәнне индереп, Пәйгамбәребезне (сгв) нык олылаган. Ул - мөселманнарның төп кануны һәм тормышка җитәкчелек итүче Китап. Йөзләрләгән мең мөселман кешесе Коръәнне яттан белә, ә Изге Китапның берничә сүрәсен һәр мөселман яттан укып бирә ала. Коръәнне укырга мөселманнар бала чактан ук өйрәнәләр. Коръәннең басылган тиражын санап-исәпләп бетерерлек түгел.

**СӨННӘТ**

Сөннәт - бар гамәлләрдә дә Пәйгамбәребез (сгв) күрсәткән юл буенча гамәл кылу дигәнне аңлата.

Сөннәт - Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сүзе, эшләгән эше һәм башка кешенең эшләгәнен хуплаган, мактаган нәрсәләр.

Аллаһы Тәгалә сөекле Пәйгамбәребезне күркәм холык булдыру өчен дә җибәргән. Изге Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтә (мәгънәсе): "Валлаһи, Аллаһның Рәсүлендә сезгә иярергә тиешле булган күркәм холык вә яхшы сыйфатлар бардыр, Аллаһтан савапны һәм ахирәттә җәннәтне өмет иткән хәлдә Аллаһны күп зекер итүче мөэминнәр өчен" ("Әхзаб" сүрәсенең 21 нче аяте).

Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) бер хәдисендә әйтелгән: "Мине яраткан кеше Аллаһны да яратыр. Ә кем дә булса миңа итагать итми икән, ул Аллаһка да итагать итмидер". Шуңа күрә без сөекле Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) тормышын яхшылап белергә тиешбез.

**Руслан хәзрәт МОРТАЗИН,**
**Татарстанның төньяк-көнчыгыш төбәге казые**

# Диния нәзарәте вәкилләре Зәй имамнары җыелышында катнашты

**21 гыйнвар көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте хезмәткәрләре Зәй мөхтәсибәтенең имамнар җыелышында катнашты.**

Көн тәртибендә - иң мөһим мәсьәләләрнең берсе - яшьләр белән эшләү юллары барланды. Зәй районы имам-мөхтәсибе Сәгыйть хәзрәт Камалов үз чыгышында мөселман яшьләре белән, шулай ук барлык конфессия вәкилләре белән һәрдаим эшләү бүгенге дин әһелләре бурычы икәнне билгеләп узды.

Хәзерге вакытта районда барлыгы 32 мәхәллә эшли. Зәй шәһәренең Җәмигъ мәчетендә һәр ел саен мәктәп яшендәге балалар өчен лагерь оештырыла, күп кенә авыл мәчетләре ял көннәрендә дини укулар үткәрә. Район мөхтәсибе Сәгыйть хәзрәт: "Эшләү дәверендә шактый зур тәҗрибә тупладык. Безне иң борчыганы - районыбызда яшь дин белгечләре җитәрлек булмау. Яшьләр арасында ныклы әйдәп баручы булмаганлыктан, бу юнәлеш аксый", - дип белдерде.

Билгеле булганча, 2012 елдан башлап Татарстан мөфтияте каналы астында эшли торган "Алтын урта" татар-мөселман яшьләр җәмгыяте республикабыз районнарында үз бүлекчәләрен булдыру юнәлешендә эш алып бара. Килгән кунаклардан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге мөдире Акйолдыз Фәизова чыгыш ясады. Ул "Алтын урта" җәмгыятенең 2012 елда башкарган эшләре белән таныштырды, Зәй районында да җәмгыять филиалы эшен башлау кирәклеген әйтте. Район хакимиятеннән килгән Фәрит әфәнде Мусин, мөфтият яшьләрен хуплап: "Максат куеп эшләргә кирәк", - дип имамнарга мөрәҗәгать итте. Сәгыйть хәзрәт, үз чиратында, яз башында якташлары Таҗетдин Ялчыгол истәлегенә "түгәрәк өстәл", соңрак - яшьләр өчен җыен үткәрү нияте барлыгын җиткерде.

Җыелышта уку-укыту мәсьәләләре буенча да фикер алышу булды. Бу уңайдан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең мәгариф һәм фән бүлеге мөдире Айдар хәзрәт Карибуллин мәчетләрдә оештырыла торган дини курсларның мөһимлеген билгеләп узды. Мондый дәресләрдә сөйләнгән һәр сүз зур әһәмияткә ия, чөнки мәчеттә белем алучыларның саны мәдрәсә-университетларда укучыларныкыннан бермә-бер күп. Айдар хәзрәт, имамнарга мөрәҗәгать итеп, уку-укыту эшендә халкыбызның бөек дин әһелләре тарафыннан язылган классик хезмәтләрне - "Гыйбадәте Ислами", "Мөгаллим сәни", "Фән Тәҗвид" китапларын һич икеләнмичә файдаланырга тәкъдим итте.

Татарстан мөфтияте нәшер итә торган "Дин вә мәгыйшәт" газетасы мөхәррире Нияз Сабирҗанов үз чыгышында Сәгыйть хәзрәткә күп имамнарга үрнәк итеп куйды. Барлык мәхәлләләрнең дә газетага язылу кампаниясендә актив катнашуын билгеләп узды һәм мөхтәсибкә рәхмәт сүзләрен җиткерде.

Мөхтәсибәтнең гыйнвар аенда уза торган чираттагы җыелышы Зәй шәһәренең Т.Ялчыгол мәхәлләсендә үтте. Киләсе җыелыш февраль аеның беренче чәршәмбесендә узар дип көтелә.

# Хәзерге шигъриятtә Мифтахетдин Акмулла образы

*Уйлыйсыздыр: адәмнәргә шагыйрьнең үзе кирәк?*
*Юк! Шагыйрьнең, үзе үлгәч, даны һәм сүзе кирәк...*

**Илдар Юзеев**

XIX йөздә татар халкының үзаңында, иҗтимагый-тарихи күзаллавында билгеле бер үзгәрешләр туа. Моңа кадәр хөкем сөреп килгән күп кенә догмаларга шикләнеп карау, кеше фикеренә, аның эшчәнлегенә хөрлек таләп итү, иҗтимагый тормышның шактый өлкәләрендә сүздән гамәлгә күчә бару хәрәкәте барлыкка килә. Мәгърифәтчелек идеяләре гадәти фикердән иҗтимагый хәрәкәткә әверелә. Шул рәвешле, киң колач җәя барган саен бу хәрәкәт тора-бара җәдитчелек дип аталган милли-мәдәни һәм социаль-иҗтимагый юнәлешле агым булып әверелә.

XIX йөз әдәбиятының зур өлешен оригиналь әсәрләр алып тора. Шигърият, проза, драма төрләренең һәрберсендә дә җанлану барлыкка килә. Гомумән, бу чор әдәбияты өчен жанр төрлелеге хас. Анда мәдхия-мәрсияләрне, сәяхәтнамә, поэма-дастаннарны да, роман һәм повестьларны, драма әсәрләрен дә очратырга була. Реалистик сюжетлы, тормышчан геройлы әсәрләр иҗат итүгә юнәлеш тотыла. Шул ук вакытта шәрык һәм гареб әдәбиятларын татар теленә тәрҗемә итү дә киңрәк колач ала.

XIX гасыр татар әдәбияты Яңарыш чоры буларак карала. Шуңа күрә, татар язучылары бу чор әдәбиятына игътибарын беркайчан да киметмәде. XX йөз башы шагыйрьләре Дәрдемәнд, Тукайлар да, хәзерге шагыйрьләр дә шул чор әдәбиятына мөрәҗәгать итәләр. Мисал өчен шагыйрә Ф.Тархановaның бер шигыренә игътибар юнәлтик:

*Унтугызынчы йөз кешесемен -*
*Яшәр идем тик шул гасырда.*
*Хөсетле һәм чирле яңа чорга*
Куркам хәтта аяк басарга.

Шигырь "Унтугызынчы йөз кешесемен" дип аталса да, шагыйрә төп фикерне XX гасырдагы проблемаларга юнәлтә. Автор шигырендә "авызын ачса, нәҗес коела торган" кеше күплегенә уфтана. Заманының көч һәм акча заманы булуын искәртә. Шигырьдә, тел сәясәте мәсьәләсенә дә игътибар ителгән. Автор, ана сөте белән керми калганга, бик күпләрнең "теле ватык", җитмәсә, "сабыйларның теле дә ямьсез", дигән фикер үткәрә. Ф.Тарханова шигырьдә сөйләм теленең сафлыгы өчен көрәшә. Тел мәсьәләсеннән соң шагыйрә киләчәк, милләт хакындагы фикерләре белән уртаклаша. "Киләчәк тә караңгы, үткәнгә дә кире кайтып булмый" - шигырьдән аңлашылган төп фикер шул.

Шагыйрә шигырьдә XIX йөзгә хас сыйфатларны күрсәтмәсә дә, бу гасырга аның уңай бәясе сизелеп тора. Чынлыкта XIX йөздә дә татар халкы милләт, тел, көнкүреш, сәясәт, икътисад проблемаларыннан котыла алмаган. XIX гасырда язма тел гади халыкка бик үк аңлаешлы да булмаган.

XIX йөзнең күренекле шагыйре Мифтахетдин Акмулланың үз әсәрләре дә өч телнең катнашмасыннан гыйбарәт. Шулай ук аның тормышы да җиңелләрдән булмаган. Шигырьләреннән аңлашылганча, ул, хәерчелек, мохтаҗлык күреп, "керле күлмәк, ертык дамбал" киеп үскән. Янәдән Ф.Тархановaның "Мин кайтыр идем" шигыренә әйләнеп кайтыйк:



*Мин кайтарыр идем*
*Милли әхлакны,*
*Борынгыдан килгән әдәпне,*
*Сөрер идем җирдән*
*Телне, милләтне*
Каралтучы барча гадәтне, -

дип яза шагыйрә. Күренгәнчә, автор зыялылыкны, "абруй саклап мәгърур йөрүне", хәтер калганда үчләшмичә, вәкарь белән китә белүне кайтарырга хыяллана. Кыскасы, ул тәрбия, әхлак мәсьәләләрен күтәрә.

Әгәр Акмулланың "Иң әүвәл кирәк нәрсә" дип башланган шигыренә игътибар итсәк, ул асыл затлар өчен алты иң кирәк әйберне санап чыга: иман, күңел, гакыл, шөкер, әдәп, сабыр. Шул ук проблемалар хәзерге заман шагыйрьләрен дә борчый.

Акмулла - эмоциональ шигъри сөйләм остасы. Ул күпвакыт әйтергә теләгән фикерен күчерелмә мәгънәдә бирә. Болай эшләү шигырьдәге идеяне төрле поэтик алымнар белән ачарга ярдәм итә, әсәрләрдә, мәгънәне көчәйтү максатыннан, чагыштырулар да нәтиҗәле файдаланыла.

*Тугры сүзгә*
*һавасы очып бара,*
*Чатнаган пыяладай*
*чытырлаган.*

Әлеге шигыре белән Акмулла байлыкның, конкрет алганда, акчаның хаклыкны әйтүгә комачаулавын һәм үз чоры кайбер укымышлыларының шул сәбәпле туры әйтүдән читтә торуларын тәнкыйть итеп чыга. Заман акча, байлык мәсьәләсенә күп кенә үзгәрешләр кертсә дә, бүген дә шагыйрьләр әлеге темага еш мөрәҗәгать итәләр.

Шигырьдәге "чатнаган пыяла" детале хәзерге заман шагыйре Р.Харисның "Империя таркалганда" исемле шигырендә дә күзәтелә. Акмулла - мәгърифәтче шагыйрь. Шуңа күрә аның шигъри детале XIX гасырдагы мәгърифәтчелек идеалына хезмәт итә. Акмулла "чатнаган пыяла" деталең "дәүләт", "тугрылык", "әхлак" төшенчәләрен яктырту өчен кулланса, Р.Харис шигырендә сүз XX гасырның сиксәненче елларындагы дәүләт, сәясәт, икътисад турында бара һәм шулай ук әхлак мәсьәләсе дә килеп керә. Дөрес, әхлак нык кына үзгәргән, кырысланган формада бирелә. Шагыйрь аны "кеше тимер торбаларны өзә тешләп" формасында сурәтләгән.

Акмулла нигездә үзе тирән кичергән нәрсәләр хакында яза. Аның иҗатында заман сулышы, авторның шәхси язмышы нык сизелә. Поэтик интонациясендә публицистик аһәң көчле. Шагыйрь еш кына үз чорының кайбер затлары белән бәхәскә керә, нәрсәнедер раслый, кире кага. Акмулла - аз сүзләр белән тирән, тапкыр мәгънә белдерү остасы. Хикмәтле сүз әйтүдә аның татар, казакъ, башкорт фольклорыннан, бигрәк тә төрки-татар язма әдәби казанышларыннан мул һәм иҗади файдалануы сизелеп тора. Аның аерым шигырь юллары, афоризмнарга әверелеп, хәзерге шигърияттә урын ала. Мәсәлән, М.Мирза аның

*Йахшыны сүккән*
*белән аты китмәс,*
*Яман сүзнең*
*күңелдән даты китмәс.*
*Саф алтынны*
*нәҗескә буяу белән,*
*Нәҗес китәр,*
*алтынның заты китмәс,* -

дигән шигырь юлларыннан, "Яман сүзнең күңелдән һич заты китмәс" әйтемен эпиграф итеп алып, "Ялган сүз" шигырен яза. Ул ялган сүзне арттан атылган агулы ук, җанга кадалган тутыккан кадак белән чагыштыра да, Акмулла кебек "тәрбияләп калырга" тырыша.

Акмулла фикеренчә, шигырьнең асылы нәсыйхәткә корылырга тиеш, шул вакытта ул буш булмый, мәгънәгә ирешә. Аның иҗатында аңа кадәр язма әдәбиятта күзгә ташланмаган, поэтик фикерне үтемле гәүдәләндергән сурәтләр шактый күп очрый. Мәсәлән, көнчеләрне, гайбәтчеләрне автор кутырлы җирне эзләп йөрүче чебенгә тиңли. "Кайда черек, кутыр бар - чебен шунда кунар", - ди ул.

М.Акмулла иҗаты - меңьеллык татар шигъриятенең мөһим буыны, традиция һәм яңалык кушылуының (синтезының) күркәм бер үрнәге. Аның әсәрләрендә XIX йөздә халкыбыз яшәешенең төрки чынбарлыгы һәм рухи тормышының әһәмиятле мәсьәләләре гәүдәләнеш тапкан.

***(Ахыры 4 нче биттә.)***

# МӘҮЛИД

**Ислам дине тотучыларның дини бәйрәмнәре шактый. Аларның кайберләре бәйрәм, икенчеләре - кичә, өченчеләре - көн дип йөртелә.**

Мөселманнарда иң олы бәйрәмнәр: Мәүлид, Ураза һәм Корбан бәйрәмнәре.

Мәүлид - Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көне һәм шул вакытта үткәрелә торган бәйрәм.

Мәүлид - гарәпчәдән "туу" дигәнне аңлата. Ул - мөселманнарның зур бәйрәмнәреннән берсе булган Мәүлид кичәсе. Икенче төрле аны Мәүлид ән-Нәби, ягъни "Пәйгамбәрнең тууы" дип тә йөртәләр. Әлеге көн, бөтен дөнья мөселманнарының дөнья вә ахирәт сәгадәтләренә сәбәп булган Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көне булу сәбәпле, мөбарәк көн исәпләнә. Бу көнне мәчетләрдә вәгазьләр сөйләнә.

Бер мөнәҗәттә мондый юллар бар:

И, кардәшләр, сөенеч безгә
- Изге Мәүлид ае туды.
Шатлык булсын барчабызга
- Изге Мәүлид ае туды.

Мәүлид аенда татар халкы яшәгән төбәкләрдә мәчетләрдә генә түгел, өйләрдә дә Мәүлид укыту, Мәүлид ашы үткәрү йолалары башкарылып килә. Иң әүвәл - салават, аннан соң зекер әйтәләр.

Татар халкының җирле үзенчәлекләрен, телне һәм йолаларны, гореф-гадәтләрне өйрәнү экспедицияләрендә йөргәндә безгә күп кенә авылларда бәйрәм үткәрүнең үзенә хас якларын язып алу да насыйп булды. Мәсәлән, Себердә - Тубыл-Иртыш якларындагы Абаул дигән авылда Мәүлид мәҗлесендә, күмәкләшеп, "Сөембикә" мөнәҗәтен әйтәләр:

Сөембикә, шатлан бүген,
Шатлана торган көнең.
Чөнки хәзрәте Мөхәммәд
Дөньяга туган бүген.

Әстерхан өлкәсенең Приволжский районы Килинчи (Киләче) авылында Мәүлид бәйрәмен бик зурлап, мәчеттә күмәк табын ясап үткәрүне күреп кайткан идек. Монда хатын-кызлар, өлкән апалар бәйрәмчә киенеп, һәркайсы шул якларга хас булган бәйрәм ашларын пешереп алып килә. Без әлеге мәкаләбездә шушы авылдан алып кайткан язмаларыбызны, Нәсимә абыстай һәм өлкән хатын-кызлар сөйләгән мәгълүматларны китерәбез.

- Менә Мәүлид аенда матур итеп бәйрәмчәйгә җыелдык.

- Идәнгә тәстәрхан җәеп, түфәк-мендәрләргә тезелеп утырып, бәйрәмашлардан авыз иттек.

- Тәстәрханыбызда бәйрәмебезне сыйлап алып килгән, кардәшләребез үзләре пешергән ашлар тезеп салынган.

- Менә пәйгамбәребезнең яраткан ризыгы хәлвә (монда һәм алга таба нинди дә булса татлы ризык күз алдында тотыла; әйтик, милли ризыкларыбыздан чәк-чәкне дә шуңа кертеп карарга була. - ред.). Аны Мөслихә тәтәбез пешереп китерә ел да.

- Менә кыздырмыш (майда пешерелгән күмәч), үзем пешердем.

- Менә бавырсаклар, бәлешләр, кәнфитләр. Бавырсакларны тәстерханга чәчеп салабыз. Һәркем авыз итсен.

- Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көнендә Коръән укыткан кеше Мәүлид аена хәлвә катыра. Болай башка вакытларда инде кеше теләсә генә катыра хәлвәне, теләмәсә, юк. Мәүлид аенда хәлвә ясарга тырышалар, ул Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) яраткан ризыгы булган. Шуның өчен хәлвә белән авыз итәләр.

Чын күңелдән тыңласаң, кил Мәүлидкә,
Укыйлар Мәүлидтә махсус каендә.



Сират кичмәгә эстәсәң, Мәүлидкә кил,
Җәннәт эстәр булсаң, ашыгып, Мәүлидкә кил.

Ошбу укыган Мәүлид догасының савабын барча өммәтләреңә насыйп әйләсәң иде.

Ошбу укыган Мәүлид догалары Кыямәт көне кояшыннан күләгә булсын, Кыямәтнең авыр сәгатендә шәфәгать булсын.

Ярабым, шушы Мәүлид аенда Мөхәммәд пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көнен котлап, шушы дин мәҗлескә, бәйрәмчәйгә җыелган дин кардәшләребез укыган намазлар, хөтбәләрнең әҗер-савабын биргәй идең.

Мәүлид айларында шушылай итеп утырмага, намазларыбызны укымага насыйп ит, Ярабби!

**Флёра БАЯЗИТОВА,**
**филология фәннәре докторы,**
**Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре**

# Иманлы кешенең сыйфатлары

**Чын иманлы кеше бу дөньяның бакый түгел, ә фани, ул бакыйлыкка күчкән вакыттагы бер чара гына һәм безгә аның белән хушлашырга туры киләчәк бер урын гына булганын яхшы аңлый. Ул үзенең кылган гамәлләре өчен Аллаһ алдында җавап тотарга туры киләчәгән бервакытта да онытмый. Шуңа күрә ул бу дөньяның һәр көненә, һәр сәгатенә, һәр мизгеленә сакчыл карый, дөньяви дәртләр вәсвәсәсенә бирелми, дөньяның бәрәкәтләрен куллану белән генә шөгыльләнми, ул үз-үзенә югары тәрбия биреп, игелекле гамәлләр кылып, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алу өчен ирешергә омтыла. Ә аның өчен үрнәк өлге булып пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) тора, чөнки ул - кешеләр арасында иң камиле, күркәм холык иясе, Аллаһның могҗизаи Яратылганы.**

Коръәндә аның турында: "Ий Мөхәммәд галәйһиссәлам, Без сине галәмнәргә рәхмәт өчен генә җибәрдек" ("Пәйгамбәрләр" сүрәсенең 107 нче аяте), - диелгән. Пәйгамбәребез (сгв) болай дигән: "Иман нуры төшкән күңелнең өч сыйфаты бар: беренчесе - ул рәнҗетми, икенчесе - ул рәнҗеми, өченчесе - ул игелекле эшләре өчен берниндидә әҗер сорамый, аны Аллаһ ризалыгы өчен генә эшли".

Болар - иманлы кешенең төп сыйфатлары. Аллаһның рәсүле Мөхәммәд (сгв) үзенең бер хәдисендә: "Дин - ул әхлаклылык", - дигән. Андый күңелгә ия булу - һәр динле кешенең чын бәхете. Шулай итеп, ислам диненең максаты - үзенең бар күңеле һәм аңы белән Аллаһка итагать итүен танучы югары әхлаклы кеше тәрбияләү.

Исламның чын максатын аңлау өчен, Аллаһ ризалыгын алу юлында бар омтылышлары да, бар Яратылганнарга да хезмәт итү, аларга Аллаһ хакыйкатьләрен җиткерүгә юнәлтелгән булган Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!), сәхабәләрнең, тәкъваларның тормышын тирәнтен өйрәнү лазем.

Исламның бер тәкъва иясе булган Мәгъруф әл-Кархи тормышыннан бер мисал китерәсем килә, ул: "Әгәр Аллаһ үз бәндәсен сөйсә, Ул аңа изге гамәлләр ишеген ачар", - дигән. Бер көнне Мәгъруф Кархиның өенә бер авыру карт килә. Мәгъруф Кархи аны ашата, ял итәргә тәкъдим итә. Бу карт остазның йортында яши башлый. Карт, төннәрен түзеп тора алмаслык авыртуларга чыдый алмаганлыктан, бик каты улый, йорт әһелләренең берсе дә тыныч йоклый алмый. Карт бик кире һәм көйсез була. Барлык кешеләргә дә кычкыра һәм барысына да комачаулый. Йорт әһелләре акрын гына йорттан китә башлыйлар. Өйдә йортның хуҗасы, ягъни Мәгъруф Кархи һәм аның хатыны гына кала. Мәгъруф Кархи көне-төне бу картка хезмәт кыла, һәрвакыт аның күңелен күрергә тырыша. Бервакыт ул, хәлсезләнеп, картның урын-җирендә йоклап китә. Карт бу хәлне күргәч: "Бу нинди кешеләр? Бу нинди монафикълар? Тыштан изгеләр булып күренәләр, ә эчтән әшәкеләр икән. Башкаларга нәсыйхәтләр бирәләр, ә үзләре шәригать боерыкларын үтәмиләр. Монысы да йоклап китте. Минем турыда бер дә уйламыйлар. Миңа ничек авыр булганын әллә белмиләр микән?" - дип ачулана башлый.

Мәгъруф Кархи бу сүзләрне тыңлый, ләкин ишетмәгән кебек аңа хезмәт кылуын дәвам итә. Ләкин аның хатыны түзә алмый һәм иренең колагына болай дип әйтә: "Ничек инде бу шыксызлыкка, ямьсезлеккә түзәргә мөмкин?! Сез ишеттегезме инде яхшылыкны белмәүче бу картның сүзләрен! Әйтегез аңа: безнең йорттан китсен! Яхшылыкның кадерен белгән кешеләргә генә ярдәм итәргә кирәк".

Мәгъруф Кархи дәшмичә хатынының сүзен тыңлый да, елмаеп: "Ни өчен син аның сүзләренә үпкәлисең? Ул миңа кычкырды, миңа карата әдәпсезлек кылды. Аның сүзләре миңа берниндизыян китермәде. Син күрәсең бит, аңа бик авыр, ул хәтта тыныч кына йоклый да алмый. Бел шуны - үзе газапланган һәм башкаларны да газаплаган кешеләргә хезмәт кылу, аларга карата миһербанлы, шәфкатьле булу - олуг бер сәнгатьтер", - дигән.

Аллаһы Тәгалә үзенең Китабында безгә болай дип мөрәҗәгать итә:

وَاعْبُدُواْ اللّهَ وَلاَ تُشْرِكُواْ بِهِ شَيْئًا وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَى وَالْيَتَامَى وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَى وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالجَنبِ وَابْنِ السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ إِنَّ اللّهَ لاَ يُحِبُّ مَن كَانَ مُخْتَالاً فَخُورًا

"Аллаһның үзенә ихлас гыйбадәт кылыгыз, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз. Ата-анага, якын кардәшләргә, ятимнәргә, мескеннәргә, кардәш булган һәм кардәш булмаган күршеләргә изгелек итегез. Шулай ук сәфәрдә булганда ят юлдашларга, үзегезгә кунак булып килгән юлчыларга һәм хезмәтче колларыгызга изгелек кылыгыз. Тәкәбберләнеп мактанучыны Аллаһ, әлбәттә, сөйми" ("Ән-Ниса (Хатыннар)" сүрәсенең 36 нчы аяте).

Аллаһы Тәгалә безнең күңелләребезне күркәм сыйфатлар белән баетса, безгә бу дөньяда да һәм ахирәттә дә бәхет-сәгадәткә ирешергә насыйп итсә иде!

**Нияз хәзрәт САБИРОВ,**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы әгъзасы, Казан ислам колледжының директор урынбасары**



# Хәзерге шигърияттә Мифтахетдин Акмулла образы

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

XX йөз башы татар шигърияте зур үсешкә ирешкән икән, моңа, әлбәттә, Акмулла иҗаты да билгеле бер йогынты ясаган. 1911-1915 елларда Троицк каласында чыккан "Акмулла" исемле көлке журналы да шагыйрь исеме белән бәйле. Акмулла еш кына үзенә һәм лирик героена карата "дәрдемәнд" сыйфатын куллана ("Мин үзем бер дәрдемәнд диванәмен", "Иншат иткүче мөләкъкаб дәрдмәнд Акмулланыз", "дәрденә дәртмәндләр шифа". XX йөз башы шагыйре Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) Акмулла иҗатын яхшы белгән, аның күп кенә традицияләрен дәвам иттергән. Бәлки, "Дәрдемәнд" псевдонимын да аның иҗаты тәэсиреннән алгандыр, дигән фикер яши.

Акмулла иҗатында шагыйрьнең биек бер ноктасы итеп бәяләнергә хаклы "Шигырь" дип исемләнгән әсәр күзәтелә. Әлеге шигырь үзенең тәнкыйди рухы, иҗтимагый актуальлеге белән укучы игътибарын җәлеп итәргә лаеклы. Әлеге шигырьдә Акмулла үз чорының төрле социаль гаделсезлектән туган торгынлык, ялагайлык, икейөзлелек кебек сыйфатларны тәнкыйтьли. Чынбарлыкны барлык дөреслеге белән тасвирлаган шигырьдә шагыйрь вөҗдан сафлыгы, тормышны пакьләү мотивын куллана. Хәлфә буларак та, шагыйрь буларак та Акмулла үзенең укучыларын юлдан, диннән читкә тайпылмаска өнди; акыллы-тәүфыйклы булырга чакыра; әдәпле-инсафлы, сабыр холыклы булырга өйрәтә.

Акмулла - суфи шагыйрь Шәмсетдин Зәкинең шәкерте. Ул аңардан Эстәрлебаш мәдрәсәсендә сабак ала. Ә инде Троицкида уку дәверендә үзе дә казакъ балаларына белем бирә һәм Карасуда төпләнеп кала. Иҗатын һәрвакыт балалар укыту белән бәйләп алып бара. Намусы пакь хәлфә миһербансызлыкка, шәфкатьсезлеккә, алдашу-гаделсезлекләргә битараф кала алмый - гади халыкны яклап, хакыйкатьне даулап, гаделлек эзләп Петербургка кадәр барып җитә. Аның кайбер байлар белән уртак тел таба алмавы иҗатында да чагыла: нинди генә яла якмасыннар, нахак бәла такмасыннар, саф алтынны һичбер вакыт пычрата алмаслар, ди ул. Утны-суны кичми торып, дөнья казанында кайнамый-пешми, чыныкмый торып, адәм баласы камил булмый, ди. Дошманнарын вак-төяк кошка санап: "Тургайның тозагына лачын төшми", - ди.

Әмма Акмулланың дошманнары "вак-төяк кошлар" булып чыкмый. Алар 1895 елның күзге караңгы бер төнендә шагыйрьне явызларча үтерәләр. Менә шул вакыйгалар "Акмулла бәете"нең нигезенә салынган да. Аны беренче тапкыр М.Госманов 1981 елда бастырып чыгарган.

Бүгенге татар шагыйрьләре арасында Акмулланың иҗатына күп игътибар итүче шагыйрьләрдән М.Әгъләмне билгеләү дөрес булыр. Аның үзен дә, Акмулла кебек, еш кына чичәнгә тиңлиләр. Ул чын чичәннәрчә иҗат итә, шигырьләрендә халык акылы югары поэтик осталык белән үрелеп бирелә, көчле фәлсәфә сизелеп тора. Р.Зәйдулла М.Әгъләм белән Акмулла арасындагы традиция бәйләнешләрен болай билгели: "Мөхәммәдьяр - Акмулла - Тукай - Туфан - М.Әгъләм".

Биредә шулай ук М.Әгъләмнең "Акмулла арбасы" поэмасы турында сүз алып бару кулай булыр. Кереш һәм өч бүлектән торган әлеге поэма татар поэзиясенең күренекле әсәрләре исемлегендә йөри. Шагыйрь һәр бүлеккә йә халык бәетеннән, йә Акмулланың үз шигырь юлларын эпиграф итеп куеп барган.

Кереш Акмулланың тормыш юлын сөйләп кенә калмый, авторның заманга биргән уй-фикерләрен дә чагылдыра. Бүгенге шигърияттне "чеметеп" алу да бар монда ("Шигырь язып Тукай булмакчылар", "Шигърияттне уртакуллар тота"), сәясәт тә бар, икътисад та. Шагыйрь Акмуллага чын Кеше итеп карый, ул шигырь генә язып калмый, шәп балта остасы да, күчмә башкорт, казакъ халкының өенә генә түгел, күңелләренә дә тәрәзә уеп бирүче дә.

Оста шагыйрь булуга М.Әгъләм ике шарт куя: беренчесе, кара эшне сөю булса, икенчесе - китап ярату. Һәр ике шартны үтәргә Акмулла арбасында мөмкинлекләр тудырылган. Шагыйрьнең 1981 елда язылган шигыре Акмулла мирасының татар халкы арасында югалмаячагына ышандыра.

Акмулла - шәхси яктан күп бәла-казаларга тарыса да, әдип буларак бәхетле кеше. Аны исән вакытта да, вафат булгач та, татарлар гына түгел, казакълар һәм башкортлар да үз шагыйрьләре итеп исәплиләр. Өч халыкның яраткан шагыйре булу - иҗат кешесе өчен зур бәхет һәм олы дәрәҗә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин, хәзерге татар шигъриятендә Акмулла образы югалмас символик образны хәтерләтә. Беришe шагыйрьләр аның дәрвишлеген үз итсә, икенчеләре афоризмнарын куллана, өченчеләре аның граҗданлык позициясен бүгенге иҗтимагый-сәяси яссылыкка күчерә. Гомумән, Акмулла шагыйрьлекнең ачы хакыйкать символы булып кала бирә.

***Фәридә ХӘСӘНОВА,***
***филология фәннәре кандидаты, Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге мөдире***

«**Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 4 (173) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35387.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 17 гыйнвар көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**